МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.05.2016______ _ г. Казань ___ _№ _под-1033/16 _

**Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен «безнең яңа укытучы» гранты турында**

Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү максатларында боерык бирәм:

1. Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын гамәлгә куярга.

2. Кушымта итеп бирелүчеләрне расларга:

2.1. Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты турында нигезләмә.

2.2. Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын тормышка ашыруның календарь планы.

2.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын алучы һәм Татарстан Республикасының Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын алучыны эшкә урнаштыручы гомуми белем бирү оешмасы арасындагы килешү формасы.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын тормышка ашыру өчен җаваплы затларга: Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын тормышка ашыруның календарь планы үтәлешен тәэмин итәргә.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм отчетлар бүлегенә (Г.Ф. Гатиятуллина): Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты чараларын финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның иң яхшыларын,

яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты турында» 19.06.2015, № под-7004/15 боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу Боерыкның үтәлеше өчен җаваплылыкны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының
2016 елның 27 маендагы
№ под-1033/16 боерыгы белән расланды

# ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫНА ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫН, ПЕДАГОГИКА КӨЛЛИЯТЛӘРЕН ТӘМАМЛАУЧЫЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫЛАРЫН, ЯШЬ АСПИРАНТЛАРНЫ ҺӘМ ФӘН КАНДИДАТЛАРЫН ҖӘЛЕП ИТҮ ӨЧЕН, «БЕЗНЕҢ ЯҢА УКЫТУЧЫ» ГРАНТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты (алга таба – Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык) белән гамәлгә куела һәм Татарстан Республикасында тормышка ашырыла.

1.2. Грантның максатлары булып торалар:

1.2.1. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында укытучылар вазифаларында эшләү өчен, педагогик эшчәнлеккә сәләтләре булган талантлы яшь белгечләрне җәлеп итү.

1.2.2. Укытучы һөнәренең абруен күтәрү.

1.3. Грантның катнашучылары:

1.3.1. Грант бирүче – Грантны гамәлгә куючы сыйфатында эш итүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

1.3.2. Дәгъва кылучы – Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 1.8 пункты билгеләгән таләпләргә туры килүче, бу Нигезләмәнең 4 нче бүлегенә тәңгәл рәвештә, Грант алу өчен конкурс узарга әзер булган физик зат.

1.3.3. Грант алучы – конкурста җиңеп, Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын тормышка ашыру буенча Республика конкурс комиссиясе (алга таба – Республика конкурс комиссиясе) карары белән Грант алучы сыйфатында расланган һәм, бу Нигезләмәнең 5.8 пунктына тәңгәл рәвештә, Эш бирүче белән хезмәт килешүе төзегән дәгъва кылучы.

1.3.4. Эш бирүче – Татарстан Республикасының бу Нигезләмәнең 1.9 пунктына туры килүче, бу Нигезләмәнең 3 нче бүлегенә тәңгәл рәвештә, конкурс узган һәм бу Нигезләмәнең 5.8 пункты күздә тоткан шартларда Грант алучы белән хезмәт килешүе төзегән гомуми белем бирү оешмасы.

1.3.5. Грант катнашучыларының үзара мөнәсәбәтләре Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Грант алучы һәм Татарстан Республикасының Грант алучыны эшкә урнаштырган гомуми белем бирү оешмасы арасында расланган форма буенча төзелгән өч яклы килешү (алга таба – Килешү) белән җайга салына.

1.4. Грант бирүче, бу Нигезләмә таләпләренә тәңгәл рәвештә, Грант бирү һәм Грантның барлык катнашучылары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча бу Нигезләмәнең 1.5 пунктында билгеләнгән вәкаләтләрне башкара.

1.5. Грант үз эченә ала:

1.5.1. Грант алучының хезмәт хакына Эш бирүчедәге төп эш урынында Грант гамәлдә булуның Килешү белән билгеләнә торган срогы дәвамында үз вазифасы бурычларын үтәгән өчен ай саен түләнүче стимул бирүче өстәмә акчаны.

1.5.2. Грант алучы – педагогик булмаган югары белем бирүче мәгариф оешмасын тәмамлаган кеше, яшь аспирант һәм фән кандидаты – өчен бер тапкыр оештырылган 500дән ким булмаган сәгать күләмендә яңа һөнәргә өйрәтүне.

1.6. Грант персональ булып тора һәм башка физик затларга тапшырылырга тиеш түгел.

1.7. Грантларның саны ел саен, бу Нигезләмәнең 3 һәм 4 нче бүлекләренә тәңгәл рәвештә уздырылган конкурсларның нәтиҗәләре буенча, Грант бирүче тарафыннан билгеләнә, ләкин елга 200 Гранттан артык түгел.

1.8. Дәгъва кылучы сыйфатында Грантта катнашуга, кайда яшәүләренә бәйсез рәвештә, югары белем бирү мәгариф оешмаларын, шул исәптән педагогик булмаган вузларны, педагогика көллиятләрен тәмамлаучылар, яшь аспирантлар, фән кандидатлары дәгъва кылырга хокуклы; алар түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1.8.1. Яшьләре 35кә җитмәгән.

1.8.2. Конкурс уздырылган моментта гомуми белем бирү оешмасында укытучы булып даими нигездә эшләмәүче яки 1 елдан кимрәк эшләүчеләр.

1.8.3. Педагогик стажлары булмаган яки педагогик стажы 3 елдан артмаганнннар.

1.8.4. Төп эш урыны итеп Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларына эшкә урнашып, Грант гамәлдә булуның Килешү белән билгеләнгән срогы дәвамында, ләкин кимендә 3 ел аларда өзлексез хезмәт эшчәнлеге йөкләмәсе белән эшләргә әзер булганнар.

1.9. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары арасындагы конкурста (алга таба – Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы) Эш бирүче сыйфатында катнашуга һәм Грант алучы белән хезмәт килешүе төзергә хокук алуга Татарстан Республикасының түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерүче гомуми белем бирү оешмасы дәгъва кылырга хокуклы:

1.9.1. Игълан ителгән уку предметы буенча укытучы вакансиясе булган.

1.9.2. Грант алучыга Грант гамәлдә булуның бөтен срогы дәвамында ел саен, укыту йөкләмәсен атнага кимендә 18 сәгатьлек итеп тарификацияләүне гарантияләүче.

1.9.3. Игълан ителүче уку предметы буенча санитария-эпидемиология хезмәте һәм янгынга каршы дәүләт инспекциясе таләпләренә туры китереп җиһазландырылган аерым укыту кабинеты булган һәм аны Грант алучыга беркетүне гарантияләүче.

1.9.4. Грант алучыны (Грант алучының гаиләсен) эшләгән чорда яшәү өчен (служебный) вакытлыча торак белән тәэмин итү турында муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты белән килешүе булган (авыл районнары өчен).

## 2. Республика конкурс комиссиясен төзү тәртибе

2.1. Республика конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 13 кеше составында төзелә.

2.2. Республика конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Республика конкурс комиссиясе составына рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары керә.

2.3. Республика конкурс комиссиясенең эше аның утырышларында башкарыла. Әгәр анда Республика конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге катнашса,

утырыш юридик хокукка ия дип санала.

Республика конкурс комиссиясенең рәисе булып Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры тора.

Республика конкурс комиссиясенең рәисе вакытлыча анда булмаган очракта, аның вазифаларын Республика конкурс комиссиясе рәисенең урынбасары үти.

2.4. Республика конкурс комиссиясенең утырышлары зарурлык булуга карап уздырыла.

2.5. Республика конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәсе төзелә, беркетмә Республика конкурс комиссиясе рәисе яисә аның утырышта рәислек иткән урынбасары һәм Республика конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.6. Республика конкурс комиссиясе утырышларын әзерләү буенча, ул кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тоту буенча эшләрне Республика конкурс комиссиясенең сәркатибе башкара.

2.7. Республика конкурс комиссиясенең карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр катнашучы әгъзаларның 50 проценттан артыгы алар өчен тавыш биргән булса, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

## 3. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары арасында Грант алучы белән хезмәт килешүе төзүгә хокук алуга конкурс уздыру тәртибе

3.1. Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы, гомуми белем бирү оешмаларының бу Нигезләмәнең 1.9 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен ачыклау максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының агымдагы елда Грантны тормышка ашыру турындагы боерыгы белән ел саен билгеләнүче срокларда уздырыла.

Гомуми белем бирү оешмалары конкурсын уздыру сроклары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына Гомуми белем бирү оешмалары конкурсын уздыру көненә кадәр бер айдан да соңламыйча урнаштырыла.

3.2. Гомуми белем бирү оешмалары конкурсында катнашуга гаризаның формасы, тапшырылырга тиешле документлар исемлеге һәм аларны бирү сроклары, Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы игълан ителгәч, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

3.3. Гомуми белем бирү оешмалары Республика конкурс комиссиясенә документлар пакетын кәгазьдә һәм электрон рәвештә 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә түбәндәге адреска тапшыра: 420111, Казан ш., Кремль ур., 9 й., 207 каб. Төшке аш вакыты: 12.00дән 13.00 сәгатькәчә; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

3.4. Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы Республика конкурс комиссиясе тарафыннан читтән торып, бирелгән документлар нигезендә, тапшырылган документларның бу Нигезләмәнең 1.9 пункты таләпләренә туры килүенә экспертиза үткәрү юлы белән уздырыла.

3.5. Гомуми белем бирү оешмалары конкурсын уздыру нәтиҗәсендә Грант алучы белән хезмәт килешүе төзергә хокуклы гомуми белем бирү оешмалары исемлеге формалаштырыла (Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре һәм укыту предметлары буенча укытучылар вазифаларына вакансияләр кисемендә).

Грант алуга Дәгъва кылучылар арасындагы конкурста җиңгән Грант алучы эшкә урнашу өчен сайлаган гомуми белем бирү оешмасы Республика конкурс комиссиясе карары белән Эш бирүче сыйфатында раслана. Республика конкурс комиссиясе карары нигезендә, Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы йомгаклары турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы чыгарыла.

Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы йомгаклары турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы имзаланган моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

3.6. Аларга карата, бу Нигезләмәнең 3.5 пунктына тәңгәл рәвештә, исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән гомуми белем бирү оешмаларына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү оешмалары конкурсы йомгаклары турында боерыгы чыгарылган көннән алып өч көнлек срокта баш тарту сәбәбенең нигезе турында язмача хәбәр җибәрелә.

3.7. Республика конкурс комиссиясе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата, Россия Федерациясе законнарына тәңгәл рәвештә, суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

## 4. Грант алуга Дәгъва кылучылар арасында конкурс уздыру тәртибе

4.1. Грант алуга Дәгъва кылучылар арасында конкурс (алга таба – Дәгъва кылучылар конкурсы) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының агымдагы елда Грантны тормышка ашыру турындагы боерыгы белән ел саен билгеләнүче срокларда уздырыла.

Дәгъва кылучылар конкурсын уздыру сроклары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына Дәгъва кылучылар конкурсын уздыру көненә кадәр бер айдан да соңламыйча урнаштырыла.

4.2. Дәгъва кылучылар конкурсында катнашуга гаризаның формасы, тапшырылырга тиешле документлар исемлеге һәм аларны бирү сроклары, Дәгъва кылучылар конкурсы игълан ителгәч, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

4.3. Дәгъва кылучылар Республика конкурс комиссиясенә документлар пакетын кәгазьдә һәм электрон рәвештә 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә түбәндәге адреска тапшыра: 420111, Казан ш., Кремль ур., 9 й., 207 каб. Төшке аш вакыты: 12.00дән 13.00 сәгатькәчә; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

4.4. Дәгъва кылучылар конкурсы ике турда уздырыла.

4.5. Беренче тур – читтән торып. Беренче тур тапшырылган документларның бу Нигезләмәнең 1.8 пункты таләпләренә туры килүенә экспертиза үткәрү юлы белән уздырыла.

4.5.1. Дәгъва кылучылар тапшырган документларны карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе аларны икенче турга кертү турында яисә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә; шул хакта язмача хәбәрнамәләр андый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Дәгъва кылучының электрон яки почта адресларына җибәрелә.

Икенче турга кертүдән баш тарту өчен нигез булып, Дәгъва кылучының бу Нигезләмәнең 1.8 пункты билгеләгән таләпләргә туры килмәве тора.

Аларга карата икенче турга кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән Дәгъва кылучыларга, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Республика конкурс комиссиясенең Дәгъва кылучыларны икенче турга кертү турында карары андый карар кабул ителгән моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

4.5.2. Беренче тур нәтиҗәләре буенча, Дәгъва кылучылар конкурсының икенче турында катнашырга хокуклы Дәгъва кылучыларның тигез дәрҗәдәге (өстенлекләрсез) исемлеге формалаштырыла.

4.6. Дәгъва кылучылар конкурсының беренче турын уздыру нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракларда, Дәгъва кылучы Республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция Республика конкурс комиссиясенең Дәгъва кылучыларны Дәгъва кылучылар конкурсының икенче турына кертү турында карары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта язмача ирекле формада Республика

конкурс комиссиясе рәисе исеменә бирелә.

4.7. Республика конкурс комиссиясе апелляция бирү срогы тәмамланган көннән алып җиде эш көне эчендә апелляцияне карый. Республика конкурс комиссиясенең апелляция буенча карарлары бу Нигезләмәнең 2.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү, Дәгъва кылучыны икенче турга үткәрү һәм, бу Нигезләмәнең 4.5.2 пунктына тәңгәл рәвештә, Дәгъва кылучыны исемлеккә кертү турында.

4.8. Апелляциянең Республика конкурс комиссиясе тарафыннан каралуы Республика конкурс комиссиясенең рәисе һәм утырышта катнашучы барлык әгъзалары имзалый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.9. Икенче тур – күзгә-күз. Икенче тур Дәгъва кылучыларның укытучы һөнәренә сәләтләрен, аларның һөнәргә яраклылыгын ачыклау максатыннан уздырыла.

Икенче тур Республика конкурс комиссиясенең беренче тур апелляциясен карап тикшерүе срогы тәмамланганнан соң башлана.

Дәгъва кылучылар конкурсының икенче турын уздыру сроклары хакында мәгълүмат, Дәгъва кылучылар конкурсының икенче турын уздыру көненә кадәр өч эш көненнән дә соңламыйча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла, шулай ук аларның электрон яки почта адресларына язмача хәбәрнамәләр җибәрү юлы белән, Дәгъва кылучыларга җиткерелә.

Икенче тур үз эченә компьютер ярдәмендә тест уздыруны һәм һөнәри-психологик әңгәмәне ала; болар Республика конкурс комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм расланган тестлар буенча уздырыла.

4.9.1. Компьютер ярдәмендә тест Дәгъва кылучыларның предметның норматив-хокукый һәм укыту-методик базасын белүләре дәрәҗәсен ачыклау максатыннан уздырыла. Компьютер тестларының нәтиҗәләре Республика конкурс комиссиясе тарафыннан коллегиаль рәвештә баллар белән бәяләнә, шуларга туры китереп, Дәгъва кылучыларның иң зур баллдан башлап иң кечкенәсенә кадәр рангларга бүленгән (өстенлекле) исемлеге формалаштырыла.

4.9.2. Һөнәри-психологик әңгәмә Дәгъва кылучыларның һөнәргә яраклылык (укытучылык эшчәнлегенә теләк һәм әзерлек, укыту предметын белү, укыту методикаларын белү, балаларның психофизик үзенчәлекләрен белү) дәрәҗәсен, педагогик осталык (укыту материалын бәян итү сәләте, оештыручылык сәләте, үз-үзеңне тоту, мөстәкыйльлек) дәрәҗәсен, һөнәр буенча планлаштыруга сәләтлелеген (максатлар куюның һәм өстенлекле бурычларны билгеләүнең төгәллеге, дәресләр үткәргәндә чараларны, ысулларны һәм һөнәри алымнарны сайлап алуның максатка ярашлылыгы) ачыклау максатыннан уздырыла. Әңгәмә нәтиҗәләре Республика конкурс комиссиясе тарафыннан коллегиаль рәвештә баллар белән бәяләнә, шуларга туры китереп, Дәгъва кылучыларның иң зур баллдан башлап иң кечкенәсенә кадәр рангларга бүленгән (өстенлекле) исемлеге формалаштырыла.

4.9.3. Дәгъва кылучылар конкурсының икенче туры нәтиҗәләре компьютер тестлары һәм һөнәри-психологик әңгәмә нәтиҗәләре буенча баллар кушу юлы белән ачыклана.

Икенче тур нәтиҗәләре буенча Дәгъва кылучыларның иң зур баллдан башлап иң кечкенәсенә кадәр рангларга бүленгән (өстенлекле) исемлеге формалаштырыла.

4.10. Дәгъва кылучылар конкурсын уздыру процедуралары бозылганда, икенче тур нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракларда, икенче турда катнашкан Дәгъва кылучы Республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция Дәгъва кылучылар конкурсы нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта язмача ирекле формада Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә бирелә.

4.11. Республика конкурс комиссиясе апелляция бирү срогы тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә апелляцияне карый. Республика конкурс комиссиясенең апелляция буенча карарлары бу Нигезләмәнең 2.7 пунктында билгеләнгән

тәртиптә кабул ителә. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне кире кагу һәм куелган балларны саклап калу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

4.12. Апелляциянең Республика конкурс комиссиясе тарафыннан каралуы Республика конкурс комиссиясенең рәисе һәм утырышта катнашучы барлык әгъзалары имзалый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.13. Дәгъва кылучылар конкурсының җиңүчеләре дип Грантларның бу Нигезләмәнең 1.7 пунктында билгеләнгән саны чикләрендә иң күп балл җыйган Дәгъва кылучылар санала.

4.14. Дәгъва кылучылар конкурсын уздыру нәтиҗәләре буенча, Конкурс җиңүчеләренә, эшкә урнашу урыны сайлау өчен, гомуми белем бирү оешмаларының бу Нигезләмәнең 3.5 пунктына тәңгәл рәвештә формалаштырылган исемлеге бирелә.

4. 15. Дәгъва кылучылар конкурсының эшкә урнашу урынын сайлаган, Эш бирүче белән хезмәт килешүе төзегән җиңүчесе, Республика конкурс комиссиясе карары белән, Грант алучы сыйфатында раслана. Республика конкурс комиссиясе карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Грантлар бирү турында боерыгы чыгарыла. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Грантлар бирү турында боерыгы аны имзалаган моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

4.16. Республика конкурс комиссиясе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

## 5. Грантны тормышка ашыру шартлары

5.1. Бу Нигезләмәнең 3 һәм 4 нче бүлекләренә тәңгәл рәвештә уздырылган конкурслар нәтиҗәләре буенча, Грантның катнашучылары расланган формадагы Килешүне имзалый.

5.2. Грант катнашучыларының хокуклары һәм бурычлары бу Нигезләмә таләпләре һәм Килешү шартлары белән билгеләнә.

5.3. Эш бирүче Грант алучыны гомуми белем бирү оешмасының аның белгечлеге буенча методик берләшмәсе эшенә җәлеп итүне оештыра.

5.4. Эш бирүче, бу Нигезләмәгә һәм Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын тормышка ашыруның расланган календарь планына тәңгәл рәвештә, Грант алучыны чараларга җәлеп итү чорына гомуми белем бирү оешмасының дәресләр расписаниесен тиешенчә үзгәртеп, Грант алучыга командировкалар (отпусклар) бирүне тәэмин итә.

5.5. Индивидуаль иҗади проектны сыйфатлы итеп төзүне тәэмин итү максатларында, Грант бирүче белән килештереп, Эш бирүче Грант алучыга укыту эше буенча директор урынбасарлары, педагоглар, «Укытучы-остаз» һәм «Укытучы-эксперт» грантларын алучылар арасыннан фәнни җитәкче беркетә.

5.6. Эш бирүче Грант алучының индивидуаль иҗади проектын төзүгә һәм аны гомуми белем бирү оешмасының укыту-методик процессына кертүгә җитәкчелек итә.

5.7. Уку елы нәтиҗәләре буенча, Эш бирүче ел саен 25 майга кадәр Грант бирүчегә Грант алучының эшчәнлеге турында объектив характеристика язып бирә һәм Грант алучы белән Килешүне алга таба озайту мөмкинлеге турында Республика конкурс комиссиясенә үз тәкъдимен кертә.

5.8. Грант алучы, Грантның гамәлдә булу срогы дәвамында, ләкин кимендә өч ел Эш бирүчедә эшләү йөкләмәсен алып, Россия Федерациясенең Хезмәт кодексына тәңгәл рәвештә, мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешманың педагогик хезмәткәре вазифасына үзе сайлаган белгечлек буенча билгеләнмәгән срокка Эш бирүче белән хезмәт килешүе төзи һәм үзенең Килешү нигезендәге йөкләмәләре буенча шартларның вакытында үтәлүен тәэмин итә.

Эш бирүче, үз чиратында, бу нигезләмәнең 1.9 пунктында күрсәтелгән таләпләрне үти һәм үзенең Килешү нигезендәге йөкләмәләренең вакытында үтәлүен тәэмин итә.

5.9. Грант алучы беренче уку елында укыту процессының нәтиҗәлелеген арттыруның инновацион ысулларын һәм технологияләрен гамәлгә кертү буенча индивидуаль иҗади проектын төзи. Проект Грант алучы тарафыннан язма эш рәвешендә башкарыла һәм, аны гомуми белем бирү оешмасының укыту процессына кертүнең укыту-методик нәтиҗәлелеген һәм социаль-икътисади яктан максатка ярашлылыгын нигезләп, тәкъдим ителүче методиканы тормышка ашыру алымнары тасвирламасын үз эченә алырга тиеш. Грант гамәлдә булган аннан соңгы уку елларында Грант алучы проектны Эш бирүченең укыту-методик процессына кертү буенча эш башкара.

5.10. Грант алучы индивидуаль иҗади проектын эшләнгән эше турында ел саен тапшырыла торган беренче отчетын биргәндә тапшыра. Аннан соң килүче отчет чорларында Грант алучы проектны гомуми белем бирү оешмасының укыту процессына кертүнең нәтиҗәләрен тапшыра.

5.11. Грант алучы узган уку елы нәтиҗәләре буенча ел саен 25 майга кадәр Грант бирүчегә эшләнгән эше турында казанышлар портфолиосы рәвешендә отчет һәм киләсе уку елына эшенең перспектив планын тапшыра.

5.12. Грант бирүче Грант алучының индивидуаль иҗади проекты темасын раслый.

5.13. Грант бирүче Грант алучының индивидуаль иҗади проектының фәнни җитәкчесе кандидатурасын килештерә.

5.14. Грант бирүче, узган уку елы нәтиҗәләре буенча ел саен, Грант алучыларның эшләнгән эшләре турында отчетларын һәм Грант алучыларның эшчәнлеге хакында Эш бирүчеләрнең объектив характеристикаларын карый, шулар нигезендә, һәр Грант алучы буенча аерым-аерым, киләсе уку елына Килешүне озайту мөмкинлеге турында, яисә Грант алучының гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча Килешүне өзү турында Республика конкурс комиссиясенә бәяләмә бирә.

Киләсе уку елына Килешүне озайту мөмкинлеге турында, яисә Грант алучының гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча Килешүне өзү турында карар Республика конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

Республика конкурс комиссиясе карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Килешүне озайту турында, яисә Грант алучының гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча Килешүне өзү турында боерыгы чыгарыла.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы аны имзалаган моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

5.15. Грант алучының гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча Килешүне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып тора:

5.15.1. Дәгъва кылучының – Дәгъва кылучылар конкурсында катнашкан чорда, Грант алучының Грантны тормышка ашыру чорында үзе турында күрәләтә ялган мәгълүматлар бирүе.

5.15.2. Грант алучының бу Нигезләмә һәм Килешү белән күздә тотылган шартларны үтәмәве.

5.15.3. Грант алучы эшенең нәтиҗәлелеге булмау (Грант алучының уку елында эшләнгән эше турында отчетын һәм Грант алучының эшчәнлеге хакында Эш бирүченең объектив характеристикасын карау нәтиҗәләренә таянып, Грант бирүче биргән бәяләмә буенча).

5.15.4. Грант алучының хезмәт эшчәнлеге хакында Эш бирүченең, характеристикада булган фактлар документлар белән расланган, канәгатьләнмәслек объектив характеристикасы.

5.16. Бу Нигезләмәнең 5.17 пункты күздә тоткан нигезләр булганда, Грант алучы Республика конкурс комиссиясенә, Эш бирүчегә һәм Грант бирүчегә, Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигезләрне раслаучы документларны кушып, Килешүнең

гамәлдә булуын туктатып тору турында язмача хәбәрләр җибәрергә хокуклы.

5.17. Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булып тора:

5.17.1. Грант алучының Эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачау итүче, медик-социаль эксперт комиссиясенең шул хактагы белешмәсе белән расланган авыруы.

5.17.2. Грант алучының балаларының (якын туганнарының) Эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачау итүче, тиешле документлар белән расланган авыруы.

5.17.3. Тиешле документлар белән расланган йөклелек, бала тудыру, бала карау буенча отпуск.

5.18. Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар Республика конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

Республика конкурс комиссиясе карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында боерыгы чыгарыла.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы аны имзалаган моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына урнаштырыла.

5.19. Грант алучыларның индивидуаль иҗади проектларына карата Республика конкурс комиссиясе бәяләмәсе нәтиҗәләре һәм аларны Эш бирүчедә сынап карау нәтиҗәләре буенча, Грант бирүче, соңыннан иң яхшыларын Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының укыту-методик практикасына кертү өчен, проектлар конкурсын гамәлгә кую турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.20. Грант бирүче һәм дәүләт финанс контроле органнары, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына тәңгәл рәвештә, Грант алучының Грант бирелү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшереп торалар.

5.21. Бу Нигезләмәнең 5.15 пункты күздә тоткан очракларда, Грант алучының гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча Килешүне өзгәндә, Грантның бирелгән суммасы, законга тәңгәл рәвештә, Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Бу Нигезләмәнең 5.17 пункты күздә тоткан очракларда, Килешүнең гамәлдә булуын әһәмиятле сәбәп аркасында туктатып торганда, Грант алучыга Грант суммасын түләү Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору срогына туктатыла.

5.22. Грантны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауның булмавы Грант бирүче инициативасы буенча Килешүне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып тора.

## 6. Грантны финанслау

6.1. Грантны тормышка ашыруга бәйле чаралар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма сметасы хисабыннан башкарыла.

6.2. Грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчаның отчет бирелә торган елда файдаланылмаган калдыгы, законга тәңгәл рәвештә, Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм<br>фән министрлыгының<br>2016 елның 27 маендагы<br>№ под-1033/16 боерыгы белән расланды

**ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫНА ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫН, ПЕДАГОГИКА КӨЛЛИЯТЛӘРЕН ТӘМАМЛАУЧЫЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫЛАРЫН, ЯШЬ АСПИРАНТЛАРНЫ ҺӘМ ФӘН КАНДИДАТЛАРЫН ҖӘЛЕП ИТҮ ӨЧЕН «БЕЗНЕҢ ЯҢА УКЫТУЧЫ» ГРАНТЫН ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ КАЛЕНДАРЬ ПЛАНЫ**

| Т-п № | Чара | Үтәү срогы | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын (алга таба – Грант) тормышка ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә | ел саен 1 февральгә кадәр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының (алга таба – ТР МһФМ) Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 2. | Муниципаль районнар башкарма комитетларының Мәгариф бүлекләре (идарәләре) начальниклары һәм Директорлар советы белән Грантны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә | ел саен 1 февральгә кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 3. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары ректорлары белән Грантны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә | ел саен 1 майга кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 4 | Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары арасында Грант алучыларны эшкә урнаштыру хокукын алуга конкурс уздыру | ел саен 1 майга кадәр | Республика конкурс комиссиясе |
| 5. | Грант турында реклама материаллары (видеороликлар, баннерлар, плакатлар, флаерлар) булдыру | ел саен 1 майга кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү идарәсе |
| 6. | Грант турында норматив-методик материалларны һәм реклама мәгълүматын ТР МһФМның югары белем бирүче мәгариф оешмаларының сайтларына урнаштыру | ел саен 1 майга кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 7. | Грант турында реклама материалларын | ел саен | ТР МһФМның Гомуми белем |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | массакүләм мәгълүмат чараларына (телевидение, радио, пресса) урнаштыру | 1 майга кадәр | бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 8. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары өчен реклама брошюрасы, мәгълүмат битләре өчен мәгълүмат материалларын тираж белән чыгару | ел саен<br>1 майга кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 9. | Дәгъва кылучылар белән һөнәри-психологик әңгәмә үткәрүнең, Дәгъва кылучылар белән компьютер ярдәмендә тест уздыруның эчтәлеген һәм критерийларын билгеләү | ел саен<br>1 майга кадәр | ТР МһФМның Өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү һәм һөнәри белем бирү сыйфатын мониторинглау бүлеге,<br>Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты (алга таба – ТР МҮИ),<br>ТР МһФМның Мәгълүмат технологияләрен үстерү һәм иминлек бүлеге |
| 10. | Педагогик белеме булмаган Грант алучыларны яңа һөнәргә өйрәтү һәм педагогик белемнәре булган Грант алучыларның квалификациясен күтәрү курслары программаларын төзү | ел саен<br>10 июньгә кадәр | ТР МҮИ,<br>ТР МһФМның Өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү һәм һөнәри белем бирү сыйфатын мониторинглау бүлеге |
| 11. | Дәгъва кылучылардан конкурста катнашуга документлар кабул итү, электрон теркәү, конкурс документларын (казанышлар портфолиосы һ.б.) карау | ел саен<br>1 июльгә кадәр | Республика конкурс комиссиясе, ТР МһФМның Мәгълүмат технологияләрен үстерү һәм иминлек бүлеге |
| 12. | Дәгъва кылучылар белән һөнәри-психологик әңгәмә үткәрү | ел саен<br>20 июльгә кадәр | Республика конкурс комиссиясе |
| 13. | Дәгъва кылучылар белән, аларның норматив-хокукый һәм предметны укыту базасын белүләрен тикшерү өчен, компьютер ярдәмендә тест уздыру | ел саен<br>10 июльгә кадәр | Республика конкурс комиссиясе |
| 14. | Грант алучыларны тантаналы итеп бүләкләү буенча чара уздыру | ел саен<br>1 сентябрьгә кадәр | ТР МһФМның Гомуми белем бирү идарәсе, ТР МһФМның Оештыру бүлеге |
| 15. | Грант алучыларны эшкә урнаштыру | ел саен<br>1 сентябрьгә кадәр | ТР МһФМның Кадрлар сәясәте бүлеге |
| 16. | Педагогик белеме булмаган Грант алучыларны яңа һөнәргә өйрәтүне һәм педагогик белемнәре булган Грант алучыларның квалификациясен күтәрү | Грантның гамәлдә булу вакыты дәвамында | ТР МҮИ,<br>ТР МһФМның Өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү һәм һөнәри белем бирү сыйфатын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | курсларын оештыру | | мониторинглау бүлеге, ТР МһФМның Кадрлар сәясәте бүлеге |
| 17. | Грант алучыларга Грантны ай саен түләүне оештыру | Грантның гамәлдә булу вакыты дәвамында | ТР МһФМның Бухгалтерлык исәбе һәм отчетлар бүлеге |
| 18. | Индивидуаль проектны төзү һәм тапшыру | ел саен 25 майга кадәр | Грант алучылар |
| 19. | Уку елында эшләнгән эш турында ТР МһФМга отчет тапшыру | ел саен 25 майга кадәр | Грант алучылар |
| 20. | Грант алучыларның эшчәнлеге турында объектив характеристикалар тапшыру | ел саен 25 майга кадәр | Эш бирүчеләр |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 27 маендагы № под-1033/16 боерыгы белән расланды

Форма

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын алучы һәм Татарстан Республикасының Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын алучыны эшкә урнаштырган гомуми белем бирү оешмасы арасында

КИЛЕШҮ № __________

Казан ш. «__» ______________ 20___ ел

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 08.05.2009, № 287 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры ____________________________ йөзендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Грант бирүче) бер яктан,

Республика конкурс комиссиясенең Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын алуга дәгъва кылучылар арасындагы конкурс нәтиҗәләрен раслау турында» «___» __________ 20___ ел, №____ боерыгы белән расланган карары нигезендә Грант алучы дип танылган Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын (алга таба – Грант) алучы (алга таба – Грант алучы)

______________________________________________________________

(Ф.И.А.)

паспорты: сериясе ___________ номеры ______________, бирү датасы ___________, кем тарафыннан бирелгән ________________________________

______________________________________________________________

икенче яктан һәм

Гомуми белем бирү оешмасы уставы нигезендә эш итүче директоры

______________________________________________________________

(Ф.И.А.)

йөзендә _______________________________________________________

______________________________________________________________

(гомуми белем бирү оешмасының атамасы)

(алга таба – Эш бирүче) өченче яктан, барысы бергә «Яклар» дип аталучылар бу Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Бу Килешүнең предметы булып, Якларның Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» грантын гамәлгә кую хакында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмасына югары белем бирүче мәгариф оешмаларын, педагогика көллиятләрен тәмамлаучыларның иң яхшыларын, яшь аспирантларны һәм фән кандидатларын җәлеп итү өчен, «Безнең яңа укытучы» гранты турында» 2016 елның 27 маендагы № под-1033/16 боерыгы белән расланган нигезләмә кысасында барлыкка килүче һәм тормышка ашырылучы үзара мөнәсәбәтләре тора.

1.2. Грант бирүче үз йөкләмәләренең бу Килешүнең 2.1 пунктына тәңгәл рәвештә үтәлүен тәэмин итә.

1.3. Эш бирүче, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына тәңгәл рәвештә, бу Килешүнең 2.5.2 пунктчасы билгеләгән хезмәт шартларын тәэмин итеп, Грант алучыны ________________________________ вазифасына

(вазифа, укыту белгечлеге)

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

(гомуми белем бирү оешмасының атамасы)

эшкә урнаштыра һәм үз йөкләмәләренең бу Килешүнең 2.5 пунктына тәңгәл рәвештә үтәлүен тәэмин итә.

1.4. ______________________________________________________________

__________________________________________________________________

(югары белем бирүче мәгариф оешмасының атамасы)

тәмамлаган, педагогик югары белеме булган (булмаган) Грант алучы Эш бирүчегә бу Килешүнең 1.3 пункты билгеләгән вазифага, белгечлек буенча һәм шартларда эшкә урнаша һәм үз йөкләмәләренең бу Килешүнең 2.3 пунктына тәңгәл рәвештә үтәлүен тәэмин итә.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ХОКУКЛАРЫ

2.1. Грант бирүче бурычлы:

2.1.1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Эш бирүче аның территориясендә урнашкан муниципаль берәмлеге бюджетына, бу Килешүнең 1.3 пунктына тәңгәл рәвештә, Грант алучының Эш бирүчедәге төп эш урынында үз вазифасы буенча йөкләмәләрен үтәве өчен бу Килешү гамәлдә булуның бу Килешүнең 9.1 пункты билгеләгән срогы дәвамында түләнә торган, Грант алучының хезмәт хакына ай саен түләүче стимул бирүче ___________________________________

(сумма сүзләр белән языла)

__________________________________________________ сум күләмендәге өстәмә акчаны түләү өчен, субсидияләр бирү буенча вәкаләтләрен башкарырга.

2.1.2. Югары педагогик белеме булмаган Грант алучыга тәэмин итәргә:

төп хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча, 500 сәгатьтән ким булмаган күләмдә ______________________________ укытучысы квалификациясе буенча

(укыту белгечлеге)

бер тапкыр яңа һөнәргә өйрәнү узуны;

югарыда күрсәтелгән өйрәнүгә бәйле чыгымнарын каплауны;

югарыда күрсәтелгән өйрәнүне узу чорында үзенең бу Килешүнең 2.1.1 пунктчасы күздә тоткан йөкләмәләрен үтәүне;

Грант алучыга игълан ителгән квалификация буенча югары педагогик белем алганлыгын раслаучы документ бирүне.

2.1.3. Югары педагогик белемле Грант алучыга тәэмин итәргә:

Россия яки чит ил мәгариф яки фәнни оешмаларында бер тапкыр өч айга кадәр сроклы стажировка (квалификация күтәрү курсларын) узуны;

югарыда күрсәтелгән стажировканы (квалификация күтәрү курсларын) узуга бәйле чыгымнарын каплауны;

югарыда күрсәтелгән стажировканы (квалификация күтәрү курсларын) узу чорында үзенең бу Килешүнең 2.1.1 пунктчасы күздә тоткан йөкләмәләрен үтәүне;

педагогик квалификациясен күтәргәнлеген раслаучы документ бирүне.

2.1.4. Грант алучы һәм Эш бирүче арасындагы низагларны, бәхәсләр һәм фикер каршылыкларын хәл итүдә ярдәм күрсәтү зарурлыгы булган очракта, бу Килешү нигезләмәләре кысасында Эш бирүче оешмасында Грант алучының мәнфәгатьләрен якларга.

2.1.5. Грант алучының индивидуаль иҗади проекты темасын расларга.

2.1.6. Грант алучының индивидуаль иҗади проектының Эш бирүче тарафыннан тәкъдим ителүче фәнни җитәкчесе кандидатурасын килештерергә.

2.1.7. Ел саен агымдагы елның 25 маена кадәр Грант алучының уку елында эшләнгән эше турында отчетын, шулай ук Эш бирүченең Грант алучы эшчәнлеге турында объектив характеристикасын карарга.

2.1.8. Бу Килешүнең 4.3 пунктында күздә тотылган нигезләрдә бу Килешүне Грант алучы гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча өзгәндә, киләсе уку елына Килешүне озайту-озайтмау турында Республика конкурс комиссиясенә 2.1.7 пунктчасы нигезендә бәяләмә бирергә.

2.1.9. Грант алучыга аның Грант алуга Дәгъва кылучылар арасындагы конкурста катнашканын раслаучы документлар һәм кирәкле башка финанс документларын бирергә.

2.2. Грант бирүче хокуклы:

2.2.1. Бу Килешүнең барлык шартларын үтәүне Яклардан таләп итәргә.

2.2.2. Әһәмиятле сәбәп буенча, бу Килешүнең 4.4 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә бу Килешүне берьяклы өзәргә.

2.2.3. Әһәмиятсез сәбәп буенча, бу Килешүнең 4.2, 4.3 пунктларында күрсәтелгән нигезләрдә бу Килешүне берьяклы өзәргә.

2.2.4. Бу Килешүне Грант алучы гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча өзгән очракта, Яклардан Грант суммасын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарып бирүне таләп итәргә.

2.2.5. Якларның бу Килешү таләпләрен үтәвен контольдә тотарга.

2.2.6. Бу Килешү нигезендә Яклардан ел саен агымдагы елның 25 маена кадәр узган уку елында эшләнгән эш турында отчетлар һәм объектив характеристикалар бирүне таләп итәргә.

2.2.7. Иң яхшыларын киләчәктә гомуми белем бирү оешмаларының укыту-методик практикасына кертү өчен, Грант алучыларның проектлары конкурсын гамәлгә куярга.

2.2.8. Яклар тарафыннан бирелүче мәгълүматларны тикшерергә.

2.2.9. Татарстан Республикасы бюджетыннан бу Килешү күздә тоткан йөкләмәләрне үтәүгә бүлеп бирелә торган акчаның максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылуын закон билгеләгән тәртиптә контрольдә тотарга.

2.2.10. Россия Федерациясе Бюджет кодексына тәңгәл рәвештә, дәүләт финанс контроле органнары белән бергәләп, Грант бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибенең үтәлүен тикшерүләр уздырырга.

2.3. Грант алучы бурычлы:

2.3.1. Бу Килешүнең шартларын үтәргә.

2.3.2. Россия Федерациясе Хезмәт кодексына тәңгәл рәвештә, бу Килешүнең 2.5.2 пунктчасы билгеләгән шартларда, билгеләнмәгән срокка Эш бирүче белән хезмәт килешүе төзергә.

2.3.3. Бу Килешү гамәлдә булуның бу Килешүнең 9.1 пункты билгеләгән срогы беткәнгә кадәр, Эш бирүче белән төзелгән хезмәт килешүен өзүгә китерүче нинди дә булса гамәлләр (яисә гамәл кылмау) кылмаска.

2.3.4. Шәхси мәгълүматы үзгәргән (фамилиясе, яшәү урыны, телефон номеры, электрон почта адресы алмашынган, аспирантурага кергән, ике эшне бергә алып бару өчен (совместительство) башка оешмаларга, шул исәптән мәгарифкә карамаганнарга эшкә урнашкан, гаилә хәле үзгәргән) очракта, эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта бу хакта Якларга хәбәр итәргә.

2.3.5. Укыту процессының нәтиҗәлелеген арттыруның инновацион ысулларын һәм

технологияләрен кертү буенча индивидуаль иҗади проект төзергә. Эшләнгән эше турында беренче еллык отчетын биргәндә, төзегән проектын Грант бирүчегә карау өчен тапшырырга. Грант бирүче гамәлгә куйган проектлар конкурсы нәтиҗәләре буенча, югарыда әйтелгән проектны бу Килешү гамәлдә булу срогы дәвамында Эш бирүченең укыту процессына кертергә.

2.3.6. Ел саен агымдагы елның 25 маена кадәр эшләнгән эше турында казанышлар портфолиосы рәвешендә отчет һәм киләсе уку елына перспектив план тапшырырга.

2.3.7. Бу Килешү күздә тоткан бурычларны үтәү мөмкин булмаган очракта, аның буенча бурычларны үтәүне кыенлаштыручы хәлләр килеп туган моменттан алып эш көннәрендә исәпләнүче егерме көнлек срокта, сәбәпләрен дәлилләп күрсәтеп, бу хакта башка Якларга язмача хәбәр итәргә.

2.3.8. Грант бирүченең соравы буенча, Россия Федерациясе Бюджет кодексына тәңгәл рәвештә, Грант бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибенең үтәлүен тикшерүләр уздыру өчен кирәкле мәгълүмат һәм документларны бирергә.

2.3.9. Бу Килешүнең 4.3 пунктында күрсәтелгән әһәмиятсез сәбәпләр буенча, бу Килешү вакытыннан алда өзелгән очракта, бу Килешү гамәлдә булуның бөтен чоры өчен хезмәт хакына ай саен түләнә торган стимул бирүче өстәмә сыйфатында алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарып бирергә.

2.4. Грант алучы хокуклы:

2.4.1. Бу Килешүнең барлык шартларын үтәүне Яклардан таләп итәргә.

2.4.2. Әһәмиятле сәбәп буенча, бу Килешүнең 4.6, 4.7 пунктларына тәңгәл рәвештә, бу Килешүне вакытыннан алда берьяклы өзәргә яки гамәлдә булуын туктатып торырга.

2.4.3. Бу Килешүнең 4.1, 4.2 пунктларында күрсәтелгән очракларда, бу Килешүне вакытыннан алда берьяклы өзәргә.

2.4.4. Төп хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча, фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә.

2.4.5. Читтән торып уку формасында яки гыйльми дәрәҗәгә дәгъва кылу өчен аспирантурага керергә.

2.4.6. Грант бирүче һәм Эш бирүче белән килештереп, бу Килешү билгеләгән шартларда яки бу Килешү таләпләреннән аерылып торучы өстәмә шартларда мөстәкыйль рәвештә һөнәри белем дәрәҗәсен, квалификациясен күтәрергә.

2.4.7. Катнашуның Грант алучының төп хезмәт эшчәнлегенә һәм бу Килешүнең үтәлешенә комачауламавы шарты белән, Грант бирүче тарафыннан тормышка ашырыла торган барлык проектларда катнашырга.

2.4.8. Грант алуга Дәгъва кылучылар арасындагы конкурста катнашканын раслаучы документлар һәм кирәкле башка финанс документларын Грант бирүчедән таләп итәргә.

2.5. Эш бирүче бурычлы:

2.5.1. Бу Килешүнең шартларын үтәргә.

2.5.2. Россия Федерациясе Хезмәт кодексына тәңгәл рәвештә, түбәндәге шартларны тәэмин итеп, Грант алучы белән билгеләнмәгән срокка хезмәт килешүе төзергә:

Бу Килешү гамәлдә булуның бу Килешүнең 9.1 пункты билгеләгән срогы чикләрендә, укыту предметы буенча уку елы дәвамында атнага 18 сәгатьтән ким булмаган күләмдә укыту йөкләмәсен тарификацияләү;

Грант алучыга беркетелүче предмет кабинеты җиһазының санитария-эпидемиология хезмәтләре һәм янгынга каршы дәүләт инспекциясе таләпләренә туры килүе;

индивидуаль иҗади проектын төзегәндә, Грант алучыга укыту-методик ярдәм күрсәтү;

Грант алучыга фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирү;

Грант алучыга һәм аның гаиләсенә эшләгән чорда яшәү өчен (служебный) вакытлыча торак бирү (авыл районнары өчен).

2.5.3. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр рәвешендә бүлеп бирелгән акча кысасында, Грант алучыга хезмәт хакына өстәмә итеп, ай саен түләнүче стимул бирүче, бу Килешүнең 2.1.1 пунктында күрсәтелгән

күләмдәге акчаны, бу Килешү гамәлдә булуның бу Килешүнең 9.1 пунктында күрсәтелгән срогы дәвамында, үз вакытында түләүне тәэмин итәргә.

2.5.4. Грант алучыны үз профиле белгечлеге буенча уку йортының методик берләшмәсе эшенә җәлеп итүне оештырырга.

2.5.5. Оешманың дәресләр расписаниесенә тиешле үзгәрешләрне кертеп, Грантны тормышка ашыруның календарь планы нигезендә, Грант алучыга бу Килешүне үтәүгә бәйле командировкалар һәм отпусклар бирергә.

2.5.6. Укыту эше буенча директор урынбасарлары, педагоглар, «Укытучы-остаз» һәм «Укытучы-эксперт» грантларын алучылар арасыннан Грант алучының индивидуаль иҗади проектының фәнни җитәкчесен беркетергә.

2.5.7. Грант алучының индивидуаль иҗади проектын төзүгә һәм Грант бирүче тарафыннан гамәлгән куелган проектлар конкурсы нәтиҗәләре буенча аны оешманың укыту-методик процессына кертүгә җитәкчелек итәргә.

2.5.8. Уку елы нәтиҗәләре буенча, Грант алучы белән Килешүне алга таба озайту-озайтмау турында бәяләмә белән, ел саен 25 майга кадәр Грант бирүчегә Грант алучының узган уку елындагы эшчәнлеге турында объектив характеристика язып бирергә.

2.5.9. Грантны түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаны максатчан файдалануга бәйле чыгымнарны тоту турында Грант бирүчегә отчет бирергә.

2.6. Эш бирүче хокуклы:

2.6.1. Бу Килешүнең барлык шартларын үтәүне Яклардан таләп итәргә.

2.6.2. Грант алучының үз вазифаи йөкләмәләрен үтәвен контрольдә тотарга.

2.6.3. Бу Килешүнең 4.1, 4.3 пунктларында күрсәтелгән очракларда, бу Килешүне вакытыннан алда берьяклы өзәргә.

## 3. ФИНАНСЛАУ ТӘРТИБЕ

3.1. Бу Килешүне финанслауга бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тотыла.

## 4. КИЛЕШҮНЕ ВАКЫТЫННАН АЛДА ӨЗҮ (ГАМӘЛДӘ БУЛУЫН ТУКТАТЫП ТОРУ) ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

4.1. Бу Килешүне Грант бирүче гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып, Грант бирүченең бу Килешү шартларын үтәмәве тора.

4.2. Бу Килешүне Эш бирүче гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып торалар:

4.2.1. Эш бирүченең бу Килешү шартларын үтәмәве.

4.2.2. Грантны тормышка ашыру чорында Эш бирүченең күрәләтә ялган мәгълүматлар бирүе.

4.3. Бу Килешүне Грант алучы гаебе аркасында әһәмиятсез сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып торалар:

4.3.1. Грант алучының бу Килешү шартларын үтәмәве.

4.3.2. Грант алуга конкурста катнашу чорында һәм (яки) Грантны тормышка ашыру чорында Грант алучының үзе турында күрәләтә ялган мәгълүматлар бирүе.

4.3.3. Грант алучының укыту-методик эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге булмау (уку елында эшләнгән эш турында отчет буенча Республика конкурс комиссиясе бәяләмәсе нәтиҗәләренә таянып).

4.3.4. Эш бирүченең Грант алучының хезмәт эшчәнлеге турында документлар белән расланган канәгатьләнмәслек объектив характеристика бирүе.

4.4. Бу Килешүне Грант бирүче инициативасы белән әһәмиятле сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып торалар:

4.4.1. Грант бирүченең бетерелүе.

4.4.2. Грантның тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау булмау.

4.5. Бу Килешүне Эш бирүче инициативасы белән әһәмиятле сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып торалар:

4.5.1. Эш бирүченең бетерелүе.

4.5.2. Эш бирүче оештырылу-штат структурасының Грант алучының штат берәмлеге кыскаруга китергән үзгәртеп оештырылуы.

4.6. Бу Килешүне Грант алучы инициативасы белән әһәмиятле сәбәп буенча вакытыннан алда өзү өчен нигез булып торалар:

4.6.1. Грант алучының педагогик хезмәт эшчәнлегенә комачаулаучы, медик-социаль эксперт комиссиясенең тиешле белешмәсе белән расланган авыруы.

4.6.2. Грант алучының балаларының (якын туганнарының) Эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлегенә комачаулаучы, тиешле документлар белән расланган авыруы.

4.7. Бу Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булып торалар:

4.7.1. Грант алучының Эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулаучы, медик-социаль эксперт комиссиясенең тиешле белешмәсе белән расланган авыруы.

4.7.2. Грант алучының балаларының (якын туганнарының) Эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулаучы, тиешле документлар белән расланган авыруы.

4.7.3. Тиешле документлар белән расланган йөклелек, бала тудыру, бала карау буенча отпуск.

## 5. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

5.1. Бу Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнарына тәңгәл рәвештә җавап тота.

5.2. Якларның берсе бу Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән очракта, үтәмәү аркасында икенче Якка китерелгән зыянны гаепле Як суд тәртибендә капларга тиеш.

5.3. Үзләренең бурычларын тулысынча яки өлешчә үтәмәүнең җиңеп булмаслык көч вакыйгалары аркасында килеп чыккан очрагында, Яклар җавап тотмый.

## 6. КИЛЕШҮНЕ ҮЗГӘРТҮ, ГАМӘЛДӘ БУЛУЫН ТУКТАТЫП ТОРУ ҺӘМ ӨЗҮ ТӘРТИБЕ

6.1. Бу Килешүне төзегәндәге шартлар Яклар килешүе буенча үзгәртелергә мөмкин.

6.2. Бу Килешүне өзү яки гамәлдә булуын туктатып тору өчен, тәкъдим итүче Як башка Якларга, тапшырылганлыгы турындагы хәбәрнамәле заказлы хат белән, өзү яки туктатып тору өчен нигезләрне раслаучы документларны кушып, язмача хәбәрнамә җибәрә. Язмача хәбәрнамәгә җавап хәбәрнамә алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче унбиш көнлек срокта бирелергә тиеш.

6.3. Бу Килешү әһәмиятле сәбәп белән өзелгән очракта, бу Килешүнең 2.1.1 пунктына тәңгәл рәвештә, хезмәт хакына өстәмә итеп, ай саен түләнә торган стимул бирүче акча сыйфатында Грант алучыга түләнгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарып бирелергә тиеш түгел.

6.4. Бу Килешүнең гамәлдә булуы әһәмиятле сәбәп буенча туктатып торылган очракта, бу Килешүнең 2.1.1 пунктына тәңгәл рәвештә, хезмәт хакына өстәмә итеп, ай саен түләнә торган стимул бирүче акчаны Грант алучыга түләү бу Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору срогына туктатыла.

6.5. Бу Килешүне Грант алучы гаебе аркасында бу Килешүнең 4.3 пункты күздә тоткан әһәмиятсез сәбәп буенча өзгән очракта, бу Килешүнең гамәлдә булу чорында хезмәт хакына өстәмә итеп, ай саен түләнә торган стимул бирүче акча сыйфатында Грант алучыга түләнгән акча тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарып бирелергә тиеш.

## 7. ФОРС-МАЖОР

7.1. Әгәр аларны үтәмәү бу Килешүне төзегәннән соң гадәттән тыш характердагы хәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан, Яклар аларны алдан белә дә, акылга муафыйк чаралар белән булдырмый кала да алмый торган җиңеп булмаслык көч вакыйгалары нәтиҗәсе булып торса, Яклар бу Килешү буенча бурычларын өлешчә яки тулысынча үтәүдән азат ителә.

Җиңеп булмаслык көч вакыйгаларына Яклар йогынты ясый алмый һәм аларның килеп чыгуы өчен җавап тотмый торган вакыйгалар (җир тетрәү, су басу, янгын, инвалидлык алу, психик авыру, забастовкалар, дәүләт хакимияте органнарының Якларның бу Килешү буенча бурычларын үтәүгә комачаулаучы карарлары яки әмерләре) керә.

7.2. Җиңеп булмаслык көч вакыйгаларын сәбәп итеп куючы Як тиеш:

7.2.1. Эш көннәрендә исәпләнүче егерме көнлек срокта бу Килешүнең 7.1 пунктында күрсәтелгән шундый вакыйгаларның килеп чыгуы турында башка Якларга язмача мәгълүмат бирергә; бу вакытта башка Якларның таләбе буенча рәсми документ бирелергә тиеш. Мәгълүмат вакыйгаларның ниндилеге турында мәгълүматларны һәм, мөмкин булса, аларның Якларның бу Килешү буенча үз бурычларын үтәвенә һәм бурычларны үтәү срогына ничек йогынты ясавын бәяләүне үз эченә алырга тиеш.

7.2.2. Әлеге вакыйгаларның тәэсире беткәч, тиз арада бу хакта башка Якка язмача хәбәр бирергә. Анда бу Килешү буенча бурычларны үтәүнең фаразланучы срогы күрсәтелергә тиеш. Әгәр хәбәр язуы җибәрелмәсә яки үз вакытында җибәрелмәсә, хәбәр язуы җибәрелмәү яки үз вакытында җибәрелмәү аркасында китерелгән зыянның аны китергән Як тарафыннан каплануы мәҗбүри.

## 8. ФИКЕР КАРШЫЛЫКЛАРЫН КАРАУ ТӘРТИБЕ

8.1. Бу Килешүдән яки аңа бәйле рәвештә, Яклар арасында килеп чыгу ихтималы булган барлык бәхәсләр һәм фикер каршылыклары сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

8.2. Сөйләшүләр юлы белән ризалыкка ирешү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр суд тәртибендә каралырга тиеш.

8.3. Бу Килешү белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе законнары нормалары кулланыла.

## 9. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ СРОГЫ

9.1. Бу Килешү аны Яклар имзалаган моменттан үз көченә керә һәм 20___ елның «____» ___________ кадәр гамәлдә була.

9.2. Узган уку елы нәтиҗәләре буенча Яклар шул ук шартларда Килешүнең гамәлдә булу срогын билгеле бер вакыт аралыгына озайту (пролонгация) турында мәсьәләне карарга хокуклы.

## 10. БАШКА ШАРТЛАР

10.1. Бу Килешү Грант алучы һәм Эш бирүче арасында Россия Федерациясе Хезмәт кодексына тәңгәл рәвештә төзелгән хезмәт килешүен алмаштырмый.

10.2. Бу Килешүгә якларның үзара ризалыгы буенча бу Килешүнең 6 нчы бүлегенә тәңгәл рәвештә кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр бу Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы өстәмә Килешү төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

10.3. Бу Килешү һәр Як өчен берәр булган, бертигез юридик көчкә ия 3 нөсхәдә рус телендә төзелде.

## 11. ЯКЛАРНЫҢ АДРЕСЛАРЫ, РЕКВИЗИТЛАРЫ ҺӘМ ИМЗАЛАРЫ

| Грант бирүче | Эш бирүче | Грант алучы |
| --- | --- | --- |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы<br>Урнашкан урыны: 420111, Казан ш., Кремль ур., 9 й.<br>Банк реквизитлары:<br>ИНН 1654002248<br>Татарстан Республикасы буенча УФК (ТР ФМ л/с 02092011000<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы л/с ЛБ007080001)<br>р/с 40201810900000000002<br>БИК 049205001<br>КПП 165501001<br>ОКАТО 92401367000<br>ОКОПФ 72<br>ОКПО 00099837<br>ОКВЭД 75.11.21<br>Керем администраторы коды: 708<br><br>Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры<br>_______Э.Н.ФӘТТАХОВ<br><br>«___» _______ 20___ ел<br>М.У. | ______________________<br>МУ атамасы<br>______________________<br>Урнашкан урыны:<br>______________________<br>______________________<br>Банк ________________<br>ИНН ________________<br>р/с ___________________<br>БИК ________________<br>КПП ________________<br>ОКАТО _____________<br>ОКОПФ _____________<br>ОКПО ______________<br>ОКВЭД ______________<br>Керем администраторы коды: ________________<br><br><br>Директор:<br>_______/ ______________<br>Имза Ф.И.А.<br><br>«___» _______ 20___ ел<br>М.У. | _____________________<br>Фамилиясе<br>_____________________<br>Исеме<br>_____________________<br>Атасының исеме<br>Банк реквизитлары:<br>_____________________<br>_____________________<br>Туган көне: ___________<br>Адресы: ______________<br>_____________________<br>_____________________<br>Паспорт: сериясе _____<br>номеры ______________<br>кем тарафыннан бирелгән _____________<br>_____________________<br>«___» _______ 20___ ел<br>ИНН ________________<br>Пенсия иминиятләштерүе таныклыгы № ________<br><br><br>______/ ______________<br>Имза Ф.И.А.<br><br>«___» _______ 20___ ел |